ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫНЫҢ
ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

КАРАР

20 ноябрь 2017 ел №74

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә 2017 нче елның
19 нчы ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан районы территориаль сайлау комиссиясе тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссиясенең беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга

референдумда 870 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 461, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 52,99% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 409ы тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 88,72% ын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 49 кеше тавыш бирде, бу 10,63% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум булып узды, референдум нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2. "2018 нче елда Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Никольский, Пятидворка, Лесные Моркваши, Покровка авылларында урамнарны яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру;

- Яр буе Морквашы авылында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, Покровка авылында янгынга каршы резервуарларны ремонтлау.;

- Пустые Моркваши бистәсендә мәктәп маршруты буенча тукталыш павильоны төзү;

- Десятидворка авылында су башнясын һәм павильонын ремонтлау.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы Югары Ослан районы территориаль сайлау комиссиясе рәисе - В.П. Постников

Татарстан Республикасы Югары Ослан районы территориаль сайлау комиссиясе Секретаре - Е.Ю. Язынина